РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Каенлынского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района
423553, Нижнекамский район,
с. Каенлы, ул. Школьная, 8

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге
Советы
423553, Түбән Кама районы,
Каенлы авылы, Мәктәп урамы, 8

тел./факс (8555) 44-98-35, электронный адрес: Prostinskoe.sp@tatar.ru,
сайт: www.prostinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

07.03.2023 ел № 1

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмалар булдыру, аларны карап тоту һәм саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 11 июлендәге 18 номерлы Каенлы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Каенлы авылҗирлеге Советы карарбирә:

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмалар булдыру, аларны карап тоту һәм саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 11 июлендәге 18 номерлы Каенлы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

10 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Яшел утыртмаларны алу гариза бирүче тарафыннан тикшерү акты нигезендә, алып ташлана торган яшел утыртмалар бәясен исәпләүнең расланган методикасы буенча исәпләнгән экологик зыян күләмендә һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге территориясендә компенсацияле яшелләндерү үткәрү акчалата яисә табигый рәвештә компенсацияле (торгызу) яшелләндерү башкару юлы белән компенсацияләнә.

Акчалата компенсация гариза бирүче тарафыннан яшел утыртмаларны алып ташлауга рөхсәт бирелгәнче башкарыла.

Натураль төрдәге компенсация гариза бирүче тарафыннан яшел утыртмаларны алып ташлауга рөхсәт бирелгән көннән бер ай эчендә башкарыла. Гамәлдәге елның 15 октябреннән соң яшел утыртмаларны алып ташлауга рөхсәт биргәндә, натураль төрдәге компенсация киләсе елның 15 апреленнән бер ай эчендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны мәгълүмат такталарында, шулай ук Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Совет Каенлынского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»

Р.Р.Гарипов